ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Зеленодольск шәһәре **КАРАР**

**25.09.2017** **№ 2445**

Зеленодольск шәһәре территориясендә көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен оештыру турында

2009 елның 28 декабрендәге«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 381-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм товарлар (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) сату тәртибен раслау турында» 2011елның 04 мартындагы 171 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы халкын авыл хуҗалыгы продукциясе, көндәлек ихтыяҗ азык-төлек товарлары белән тәэмин итүне яхшырту максатларында, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2017 елның 09 сентябрендәге 36-1нче номерлы киңәшмә беркетмәсенең 3 пунктын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2017 елның 10 октябреннән 2017 елның 1 декабренә кадәр Зеленодольск шәһәре территориясендә көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен оештырырга һәм уздырырга.
2. Көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен оештыру буенча чаралар планын 1 нче кушымтада каралганча расларга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белән берлектә 2017 елның 10 октябреннән 2017 елның 1 декабренә кадәр «Табигать бүләкләре» ваклап сату базары янындагы территориядә авыл хуҗалыгы продукциясен һәм көндәлек ихтыяҗның азык-төлек товарларын сату буенча көзге ярминкәләр (К.Маркс ур., 39) оештырырга.
4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә авыл хуҗалыгы предприятиеләре ярминкәләрендә катнашу графигын булдыруны тәкъдим итәргә.
5. «Основа» ҖЧҖ җитәкчесе Ю.Г. Мельниковка 2017 елның 10 октябреннән 2017 елның 1 декабренә кадәр «Сәүдә йорты» ТК (Комаров ур., 21а) авыл хуҗалыгы мәйданчыгында авыл хуҗалыгы ярминкәсен оештырырга һәм уздырырга тәкъдим итәргә, халыкка авыл хуҗалыгы продукциясен сату өчен кирәкле шартлар белән тәэмин итәргә, районның авыл хуҗалыгы

предприятиеләрен, юридик затларны, ярминкәдә катнашучы гражданнарны, бер тапкыр җыела торган җыемнардан һәм сәүдә хезмәтләре өчен түләүдән азат итәргә.

6. Ярминкәләр уздыру урыннарында авыл хуҗалыгы продукциясе белән сәүдә итү транспорт чараларыннан һәм лотоклардан бары тик билгеләнгән урыннарда гына, тиешле теркәлгән документлары һәм сәүдә урынын тиешенчә тоткан очракта гына рөхсәт ителә дип билгеләргә.

7. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

7.1. Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлегенә көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен оештыру урыннарында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү чараларын үткәрергә;

7.2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлегенең юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе автотранспорт чараларын урнаштыруда ярминкәләрдә катнашучыларга ярдәм күрсәтергә;

7.3. Зеленодольск районы дәүләт ветеринария берләшмәсенә, ТР (Татарстан) буенча Роспотребнадзор идарәсенең Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарындагы территориаль бүлегенә ярминкәләрдә сатыла торган продукциянең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына карата гамәлдәге законнар таләпләрен үтәүне тәэмин итә торган чаралар күрергә.

8. Зеленодольск муниципаль районының авыл җирлекләре Башкарма комитетларына шундый ук хокукый актлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

9. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 сентябрендәге 2445 номерлы карарына
1 нче кушымта

Көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен оештыру буенча
ЧАРАЛАР ПЛАНЫ

1. Зеленодольск шәһәре территориясендә көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен (алга таба - ярминкә) үткәрү өчен түбәндәге чараларны күрергә:

1.1. Зеленодольск шәһәре территориясендә көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен оештыру тәртибен 1 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

1.2. «Табигать бүләкләре» ваклап сату базары янындагы территориядә оештырылган ярминкәдә билгеле бер төр товарларны (эшләрне башкару, хезмәтләр күрсәтү) сату өчен урыннар урнаштыру схемасын 2 нче кушымтада каралганча билгеләргә.

1.3. Ярминкәдә катнашуга язма гаризаларны теркәүне тәэмин итәргә.

1.4. Ярминкәдә катнашучы хуҗалык субъектлары тарафыннан сәүдә урынын җыештыруны һәм каты көнкүреш калдыкларын чыгаруны тәэмин итәргә.

1.5. Ярминкәдә сатыла торган товарлар ассортименты үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

1.6. Ярминкәдә билгеле бер төр товарларны сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) өчен ярминкәдә катнашучылар биләгән урыннарның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге башлыгы Д.Г. Низамовны көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен оештыру буенча чаралар планының үтәлеше өчен җаваплы дип билгеләргә.

Зеленодольск шәһәре территориясендә көзге авыл хуҗалыгы ярминкәләре оештыру чаралары планына
кушымта

Зеленодольск шәһәре территориясендә
көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен оештыру
ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен оештыру тәртибе (алга таба – Ярминкә) 2009 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 381-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011елның 4 мартындагы 171 номерлы карары белән эшләнгән.
1.2. Ярминкә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан оештырыла (юридик адресы: ТР, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты).
1.3. Ярминкә тибы - махсуслаштырылган (авыл хуҗалыгы).
1.4. Ярминкәнең төре - тематик.
1.5. Ярминкәнең эш режимы:

- сезон буенча һәм 2017 елның 10 октябреннән 2017 елның 1 декабренә кадәрге чорга товарларның сезонлы төрен (эшләрне башкару, хезмәт күрсәтү) сату максатларында оештырыла;
- Ярминкәнең эш режимы: 9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;
- ярминкә адресы: Зеленодольск шәһәре, К.Маркс ур., 39 нчы йорт, «Табигать бүләкләре» ваклап сату базары янында;
- сәүдә урыннары саны - 40 берәмлек.

1.6. Ярминкәдә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, шулай ук бакчачылык һәм яшелчәчелек яисә авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү белән шөгыльләнүче крестьян (фермер) хуҗалыгы, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар катнаша ала.
1.7. Сәүдә урыннары ярминкәдә товарларның билгеле бер төрләрен сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) өчен урыннар урнаштыруның расланган схемасына, сатып алучыларны ирекле үтеп керү һәм товарлар сату урыннарына керү мөмкинлегенә туры китереп урнаштырыла.

## 2. Ярминкә эшчәнлеген оештыру

2.1. Ярминкәне оештыручының бурычлары:

- Ярминкәдә катнашу өчен товарлар җитештерүне, эшләр башкаруны һәм хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны, шулай ук бакчачылык һәм яшелчәлек яки авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү белән шөгыльләнүче крестьян (фермер) хуҗалыгы, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарны җәлеп итә.
- Ярминкәне уздыру турында массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштыра;
- Ярминкәне уздыру урынында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итә;
- сәүдә урыннарының санитар-техник торышын тәэмин итә;
- ярминкә уздыру урыннарын ярминкәне оештыручы, сәүдә урыннарын урнаштыру схемасы, ярминкәнең эш вакыты һәм режимы турында мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стенды белән җиһазландыруны тәэмин итә;
- ярминкәне уздыру урыннарын ярминкәнең барлык чоры дәвамында санитария кагыйдәләре таләпләренә туры китереп чүп-чар һәм бәдрәф җыю контейнерлары белән тәэмин итә, чүп-чарны җыюны һәм чүп чыгаруны оештыра;
- ярминкә территориясендә һәм анда урнаштырылган объектларда инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен уңай шартлар тудыра;
- ярминкә уздыру чорында автотранспорт чараларын вакытлыча туктап тору өчен урыннар булдыруны тәэмин итә;
- ярминкәдә катнашучыларның үткәрелгән урынында җиһазларын һәм мөлкәтен саклауны оештыруны тәэмин итә;
- кергән гаризаларны карый, аларны теркәүне гамәлгә ашыра;
- ярминкәләрне урнаштыруны ярминкәдә сәүдә урыннарын урнаштыру схемасы нигезендә тәэмин итә;
- Ярминкәдә сәүдә урыны бирү турында шартнамә төзи;
- кулланучыларның хокукларын яклау, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге, ветеринария, әйләнә-тирә мохитне саклау, террорчылыкка каршы һәм янгын куркынычсызлыгы, җәмәгать тәртибе, монополиягә каршы таләпләр, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның хезмәт эшчәнлеге өлкәсендәге гамәлдәге законнарда билгеләнгән нормаларны үтәүне тәэмин итә.

2.2. Ярминкәдә катнашучының бурычлары:
- кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә гамәлдәге законнарда билгеләнгән таләпләрне үтиләр, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген, террорчылыкка каршы һәм янгын куркынычсызлыгын, ветеринарияне, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итәләр;
- товар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) һәм аларны җитештерүчеләр турында кирәкле һәм дөрес мәгълүматны сатып алучыларга җиткерә;
- ярминкә уздырган вакытта һәм ул тәмамланганнан соң сәүдә ноктасының тиешле санитар торышын тәэмин итә.

## 3. Ярминкәдә товарларны сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) өчен урын бирү тәртибе

3.1. Ярминкәдә катнашырга теләүче зат (мөрәҗәгать итүче) товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) өчен урын бирү турында гариза белән ярминкә оештыручыга мөрәҗәгать итә (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта).

3.2. Гаризага түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган документларның күчермәләре теркәлә:

- юридик затлар өчен-юридик затның атамасы һәм оештыру-хокукый формасы, аның урнашу урыны, юридик затны булдыру турында язманың дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең идентификация номеры;

- индивидуаль эшкуар өчен-физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, аның яшәү урыны, аның шәхесен таныклаучы документ мәгълүматлары, индивидуаль эшкуарны дәүләт теркәве турында язманың дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең идентификацион номеры;

- граждан өчен - физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны, шәхесен таныклый торган документ мәгълүматлары.

3.3. Товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) өчен урын бирү турындагы карар Ярминкәне оештыручы тарафыннан кабул ителә.

3.4. Товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) өчен урын бирү срогы ярминкәне оештыручы тарафыннан билгеләнә.

3.5. Ярминкәдә сәүдә урыннары бушлай бирелә.

3.6. Алкогольле һәм тәмәке продукциясен, шулай ук ирекле сату гамәлдәге законнар белән тыелган яки чикләнгән товарларны ярминкәләрдә сату рөхсәт ителми.

3.7. Ярминкәдә сәүдә урыны бирү турында шартнамә төзү сәүдә эшчәнлеге башлануга нигез булып тора (әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта).

3.8. Товарларны сату өчен урын бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

- товарлар (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү)сату өчен урыннар булмау;

- Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау.

## 4. Җаваплылык һәм контроль

4.1. Ярминкәдә катнашучының, товарларны сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) эшчәнлеген турыдан-туры гамәлгә ашыручының, әлеге Тәртип таләпләрен бозуы Ярминкәдә катнашучыны сәүдә итү өчен урынсыз калдыру өчен нигез булып тора.

4.2. Юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар сатыла торган продукциянең сыйфаты, сәүдә кагыйдәләрен бозган өчен, гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә башка хокук бозулары өчен җавап тоталар.

4.3. Ярминкәдә сәүдә эшчәнлеген регламентлаучы кагыйдәләрнең, таләпләрнең һәм нормаларның үтәлешен контрольдә тоту үз компетенциясе чикләрендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла

4.4. Сәүдә урыннарын урнаштыру схемасында каралмаган рәвештә оештыру һәм бирү рөхсәт ителми.

Зеленодольск шәһәре территориясендә
көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен
оештыру тәртибенә
1 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының җитәкчесенә
_______________________________________
__________________________________

Көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсендә
сәүдә урыны бирүгә
Г А Р И З А

_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
(ЮЗ өчен - предприятие исеме, ИП һәм физик затлар өчен - Ф.И.Ат.и.)
___________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
(юридик адрес, контакт телефоны)
_______________________________________________________________________
(продукция , эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү төре )

_______________________________________________________________________
адресы буенча көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсендә сәүдә урыны бирүегезне сорыйм.

Имза __________________ / ______________________

"_____" ____________ 2017 ел

Зеленодольск шәһәре
территориясендә көзге авыл
хуҗалыгы ярминкәсен оештыру
тәртибенә
2 нче кушымта

ЯРМИНКӘДӘ СӘҮДӘ УРЫНЫ БИРҮ ТУРЫНДА ШАРТНАМӘ № ____

____________________ш._____
"_____"____________ ______

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты ________________ ____________, нигезендә эш итүче________________________________________, алга таба **«Ярминкә оештыручысы»** дип аталучы, бер яктан, һәм ____________________________________________________________йөзендә ________________________________________, нигезендә эш итүче____________________________________, алга таба «**Ярминкәдә катнашучы»** дип аталучы, икенче яктан, алга таба **«Яклар»** дип аталучы, әлеге Шартнамәне, алга таба түбәндәгеләр турында «Шартнамә» төзеделәр

## 1. ШАРТНАМӘ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Ярминкәне оештыручы ярминкәләр уздыруны оештыра, адресы буенча сәүдә урыны бирә: ___________________________________________________________һәм ярминкәдә катнашучылар арасында да, алар белән өченче затлар арасында да үзара файдалы сәүдә шартнамәләре төзүгә ярдәм итә, ә Катнашучы ярминкәгә алга таба сату өчен товарлар (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) бирә.

## 2. КАТНАШУЧЫ БУРЫЧЛАРЫ

**Катнашучы үз өстенә түбәндәге йөкләмәләрне ала:**

2.1. Ярминкәдә сату өчен әлеге шартнамәгә, әлеге шартнамәнең аерылгысыз өлеше булган исемлеккә ярашлы рәвештә, товарлар (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) бирә.

2.2. Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә гамәлдәге законнарда билгеләнгән таләпләрне үти, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген, террорчылыкка каршы һәм янгын куркынычсызлыгын, ветеринарияне, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итә.

## 3. ЯРМИНКӘНЕ ОЕШТЫРУЧЫ БУРЫЧЛАРЫ

**Ярминкәне оештыручы түбәндәге йөкләмәләрне үз өстенә ала:**

3.1. Ярминкәнең уңышлы эшләве өчен шартлар тәэмин итә.

3.2. Ярминкә үткәрелгән урында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итә.

4. ШАРТНАМӘНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ СРОГЫ

4.1. Әлеге шартнамә имзаланган көннән башлап «___»____________ елга кадәр гамәлдә.

5. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

5.1. Әлеге шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен Ярминкәне оештыручы һәм катнашучы РФ законнары һәм әлеге шартнамә нигезендә җавап тота.

ЯКЛАРНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ ҺӘМ ИМЗАЛАРЫ

| ЯРМИНКӘНЕ ОЕШТЫРУЧЫ | ЯРМИНКӘДӘ КАТНАШУЧЫ |
| --- | --- |
| Имза: | Имза: |

Зеленодольск шәһәре территориясендә
көзге авыл хуҗалыгы ярминкәсен оештыру
тәртибенә
2 нче  кушымта

**кадәр**